КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 30 гыйнвар г.Казань № 47

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән көндезге формада белем алучы студентларга дәүләт академик стипендиясен, студентларга дәүләт социаль стипендиясен, аспирантларга, ординаторларга, ассистент-стажерларга дәүләт стипендиясен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 27 февраль, 121 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән көндезге формада белем алучы студентларга дәүләт академик стипендиясен, студентларга дәүләт социаль стипендиясен, аспирантларга, ординаторларга, ассистент-стажерларга дәүләт стипендиясен билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән көндезге формада белем алучы студентларга дәүләт академик стипендиясен, студентларга дәүләт социаль стипендиясен, аспирантларга, ординаторларга, ассистент-стажерларга дәүләт стипендиясен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 27 февраль, 121 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 18 октябрь, 755 нче; 2017 ел, 19 июнь, 392 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1119 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән көндезге формада белем алучы студентларга дәүләт

академик стипендиясен, студентларга дәүләт социаль стипендиясен, аспирантларга, ординаторларга, ассистент-стажерларга дәүләт стипендиясен билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктта:

беренче абзацта «студентлар советы» сүзләрен «белем алучылар советы» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «студентлар советы» сүзләрен «белем алучылар советы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктта «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин